СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.10.2020 ел** **Болгар ш.** **№2-8**

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы регламенты турында» 2005 елның 02 декабрендәге 3-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы регламентына Үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы регламентын гамәлдәге законнар нигезендә һәм коррупциоген факторларны төшереп калдыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы регламенты турында» 2005 елның 02 декабрендәге 3-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 3 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ябык утырышны уздыру турында карар кабул иткәндә, фикер алышулар ачыла.».

1.2. 6 статьяның 2 пунктында «гамәлгә ашырырга мөмкин» сүзләрен «гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 15 статьяның 4 пунктында «туктатылырга мөмкин» сүзләрен «туктатыла» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 15 статьяның 5 пунктында «теләсә кайсы вакытта чакыртып алынырга мөмкин» сүзләрен «чакыртып алынула» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 23 статьяның 1 пунктында «кирәк булганда, булдырырга мөмкин» сүзләрен «булдырырга хокуклы» сүзләре белән алыштыра.

1.6. 26 статьяның 1 пунктында «кирәк булган саен, ләкин» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.7. 34 статьяның 3 пунктында «чыгыш ясарга мөмкин » сүзләрен «чыгыш ясый» сүзләренә алмаштырырга, һәм «бирелергә мөмкин» сүзләрен «бирелә» сүзләренә алмаштырырга.

1.8. 36 статьяның 3 пунктында «шулай ук мәхрүм ителергә мөмкин» сүзләрен «мәхрүм ителә» сүзләренә алмаштырырга.

1.9. 37 статьяда «бетерелергә мөмкин» сүзләрен «юкка чыгарыла» сүзләренә алмаштырырга.

1.10. 39 статьяның 3 пунктында «үткәрелергә мөмкин» сүзләрен «үткәрелә» сүзләренә алмаштырырга.

1.11. 39 статьяның 1 пунктында «кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.12. 39 статьяның 1 пунктында «билгеләнергә мөмкин» сүзләрен «билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга.

1.13. 39 статьяның 1 пунктында «үткәрелергә мөмкин» сүзләрен «үткәрелә» сүзләренә алмаштырырга.

1.14. 39 статьяның 1 пунктында «билгеләнергә мөмкин» сүзләрен «ачыклана» сүзләренә алмаштырырга.

1.15.39 статьяның 5 пунктында «кабул итә алалар» сүзләрен «кабул итәләр»сүзләренә алмаштырырга.

1.16. 49 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Комиссия экспертизага норматив хокукый акт проектын җибәрергә, Районның Башкарма комитеты бәяләмәләрен, дәүләт органнары фикерен соратып алырга хокуклы».

1.17. 49 статьяның 6 пунктында «хокуклы» сүзләрен «хокуклы» сүзләренә алмаштырырга.

1.18. 51 статьяның 2 пунктында «кагыйдә буларак» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.19. 53 статьяның 3 пунктында «төзәтмәләр белән килешергә һәм тәкъдим итәргә мөмкин» сүзләрен «төзәтмәләр белән килешә һәм тәкъдим итә» сүзләренә алмаштырырга.

1.20.55 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Район уставы проекты, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары проекты Район башлыгы, район Советы депутатлары, район башкарма комитеты җитәкчесе. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре.».

1.21. 55 статьяның 3 пунктында «төзелергә мөмкин» сүзләрен «төзелә» сүзләренә алмаштырырга һәм «чакырылырга мөмкин» сүзләрен «чакырыла» сүзләренә алмаштырырга.

1.22. 79 статьяның 1,3 пунктларында «кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Спас муниципаль районы
башлыгы урынбасары С.И. Тюнев